СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

**25.08.2015** пос. Октябрьский **55-276**

«Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүләрен тикшерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 17 ноябрендәге 46-232 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 6 өлеше, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясындагы 8 өлеше нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүләрен тикшерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 17 ноябрендәге 46-232 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының закон, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш.Р. Азизов